ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 595 2017 елның 28 сентябре

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 472 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы торак пунктларының иҗтимагый кулланылыштагы урыннарында беренчел янгын сүндерү чаралары исемлеген раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында 2014 елның 18 декабрендәге 35 номерлы килешү нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 472 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы торак пунктларының иҗтимагый кулланылыштагы урыннарында беренчел янгын сүндерү чаралары исемлеген раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Түбән Кама шәһәренең иҗтимагый кулланылыштагы урыннарында беренчел янгын сүндерү чаралары исемлеген раслау турында».

1.2. «Түбән Кама шәһәре территориясендә гражданнарга алар милкендә (файдалануда) булган урыннарда һәм корылмаларда булдырырга тәкъдим ителгән беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь исемлеген расларга ( 1 нче кушымта)».

1.3. Карарны түбәндәге редакциядә 4, 5 пунктлар белән тулыландырырга:

«4. Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре һәм Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетларына гражданнарга җирлек территорияләрендә алар милкендә (файдалануда) булган урыннарда һәм корылмаларда беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь исемлеген расларга тәкъдим итәргә.

5. Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы авыл торак пунктларының гомуми кулланылыштагы территорияләрендә җиһазландырылырга тиешле беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь исемлеген тәкъдим ителгән форма буенча расларга тәкъдим итәргә (2 нче кушымта).».

1.4. Карарның 4, 5 пунктларын 6, 7 пунктлары дип санарга.

1.5. Карарга 1 нче кушымтада атамасында «Түбән Кама муниципаль районы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәре» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. Карарга 2 нче кушымтаны кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А. Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 28 сентябре
595 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы авыл торак пунктларының гомуми кулланылыштагы территорияләрендә җиһазландырылырга тиешле беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарьнең тәкъдим ителгән исемлеге

| п/п | Беренчел янгын сүндерү чаралары, механикалаштырылмаган корал һәм инвентарь исемлеге | Янгын щитын комплектация ләү нормалары |
|---|---|---|
| | Янгын сүндергечләр (тәкъдим ителә торган):<br>- 10 л сыйдырышлы һава-күбекле (ОВП);<br>- порошоклы (ОП)<br>сыйдырышлыгы, л / янгын сүндерү составы массасы, кг<br>ОП-10/9<br>ОП-5/4 | <br>2<br><br><br>1<br>2 |
| | Лом | 1 |
| | Чиләк | 1 |
| | Багор | 1 |
| | Асбест тукымасы, тупас тукыма яки киез (киез, янмый торган материалдан япма) кимендә 1х1 м | 1 |
| | Штыклы көрәк | 1 |